# АЕРЫЛМАГЫЗ

*Гөлшат Зәйнәшева*
*Чулпан Зиннәтуллина көе*

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

*Кушымта:*
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Канатларны каера ул
Аерылу сәгатьләре.

Ят кошны пар итмәс аккош
Ялгыз канат какса да.
Без дә бергә булалмабыз
Сулар үргә акса да.

*Кушымта:*
Ялгыз аккош күргән саен
Өзелә бәгырьләрем.
Ннгә без бергә чакларның
Белмибез кадерләрен?!

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

*Кушымта:*
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре,
Гомерләрне кыскарта ул
Аерылу сәгатьләре.